ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 23 » июнь 2018 ел № 104

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органына караган оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органына караган оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен расларга (Кушымта).

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

2.1. ведомство карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчеләрен әлеге карар белән таныштырырга;

2.2. җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар (учреждениеләр) уставларына, шулай ук аларның җитәкчеләре белән төзелгән, ведомство карамагындагы оешма җитәкчесенең хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында җирле үзидарә органы җитәкчесенә хәбәр итү бурычын билгели торган хезмәт шартнамәләренә үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы ярдәмчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы Р.Р. Нотфуллин